ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИМСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.02.2025 Бима авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бимаавыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 22.02.2024 елның 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәрби исәпкә алу турындагы нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге территориясендә гражданнарны беренче хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Бима авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 2 бүлекнең 5 пунктындагы пунктчада түбәндәге эчтәлекле «хәрби комиссариатлар булмаган җирдә» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Бима авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Э.И. Михайлов